«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 апрелендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты карары

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 апрелендәге 92-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә :

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 2 апрелендәге 69 номерлы карары (Апас муниципаль районы башкарма комитетының 24.05.2018ел, 101 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктчаның 10.6 пунктында үз көчен югалткан дип танырга;

9.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«9.6.Юридик затка, шәхси эшкуарга яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсенә бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты картасы аның гамәлдә булу срогын озайткан, транспорт чарасының билгеләнгән тәртиптә үзгәртелгән яисә характеристикасы, үзгәртеп кору рәвешендә юридик затны үзгәртеп төзегән, аның исемен үзгәрткән, шулай ук яшәү урыны адресы, һәм (яисә) фамилиясе, һәм (яисә) исеме, һәм (яисә) шәхси эшкуарның атасының исеме үзгәргән очракта, мондый шартнамәдә катнашучыларның берсе үлеменә бәйле рәвештә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның составы үзгәргән очракта яңадан рәсмиләштерелергә тиеш.»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

Җитәкче А. А. Тугушев